# ГАЛӘМ

**МӘКТӘП ГАЗЕТАСЫ**

**№1**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЮЛСУБИНО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

*СЕНТЯБРЬ 2017 ЕЛ*



## Белем бәйрәме.

Көзнең иң көтеп алган бәйрәмнәрнең берсе - 1 нче сентябрь. Менә безнең мәктәп балалары да чәчәк бәйләмнәре тотып,мәктәпкә җыелды. Укучыларның йөзләрендә елмаю, ә күзләрендә укырга теләк иде. Алар белән бер рәттән сөенеп утыручы әти-әниләре дә аз булмады. Яңа уку елы безгә бары тик шатлык, бәхет алып килсен иде.

## Сәламәт булыгыз!

Грипп үткен йогышлы сулыш авыруы. Бу чир белән һәрбер кеше дә үз гомерендә бер тапкыр булса да очраша. Һәм бу шаккаткыч түгел, чөнки грипп иң таралган йогышлы авыруларның берсе. Шуңа күрә аның турында яхшырак белергә кирәк: нәрсәсе белән куркынычлы,ничек аннан сакланырга һәм ничек җиңелрәк үткәрергә. Шушы грипптан саклану кысаларында Чәршәмбе көнне авылыбызның фельдшеры авыруга каршы привикалар ясады. Аны 97% укучы ясатты.





## Сәламәтлек сәгате.

2012 нче елдан башлап мәктәп директоры Нияз Ильязович инициативасы белән “Сәламәтлек сәгате” оештырылган иде. Мәктәбебездә бу традиция быел да дәвам итә. Спорт-сәламәтлек чыганагы, ә сәламәтлек ул-бәясез байлык.

Әлеге чараны кизү торучы сыйныф укучылары үткәрү- быелгы уку елының яңалыгы.

## БАКЧАДА КӨЗГЕ ЭШЛӘР ДӘВАМ ИТӘ.

“25 НЧЕ СЕНТЯБРЬ КӨННЕ ДӘ ТӘҖРИБӘ УЧАСТОГЫНДА ЭШ ДӘВАМ ИТТЕ. АЗЫК ЧӨГЕНДЕРЕ Һ.Б. КУЛЬТУРАЛАР ҖЫЕП АЛЫНДЫ. САРЫМСАК УТЫРТУ ӨЧЕН ТУФРАК ӘЗЕРЛӘНДЕ. УКУЧЫЛАР ҺӘМ УКЫТУЧЫЛАР ТЫРЫШЛЫГЫ БЕЛӘН КЫШЛЫК ЗАПАС ӘЗЕРЛӘНДЕ. БАРЫГЫЗГА ДА БИК ЗУР РӘХМӘТ.





## МЧС ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ БЕЗДӘ КУНАКТА

БУ АТНАДА МЧС ХЕЗМӘТКӘРЕ КАРИМОВ ИЛЬШАТ ФӘНИСОВИЧ БЕЛӘН ЧИРАТТАГЫ ОЧРАШУ БУЛДЫ.УЛ БЕЗНЕ “СУЛЫКЛАРДА ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ “ БЕЛӘН ЯНӘДӘН БЕР КАТ ТАНЫШТЫРЫП УЗДЫ.ТӨРЛЕ МИСАЛЛАР КИТЕРЕП АВЫР ХӘЛЛӘРДӘН ЧЫГУ ЮЛЛАРЫН АҢЛАТТЫ.

**БЕЗ СПОРТНЫ ЯРАТАБЫЗ**

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ СПОРТ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘ УҢЫШЛАРЫ БЕЛӘН СӨЕНДЕРЕП ТОРАЛАР. МУБАРАКОВА ЗӘМИРӘ РАЙОН БУЕНЧА УЗГАН ЯРЫШТА ЙӨГЕРҮ БУЕНЧА 2 НЧЕ УРЫННЫ АЛЫП КАЙТТЫ. АФӘРИН ЗӘМИРӘ! АЛГА ТАБА ДА ЯҢА ҖИҢҮЛӘР БЕЛӘН СӨЕНДЕРСӘҢ ИДЕ



## -КАРМАК

МӘКТӘП- ИКЕНЧЕ ЙОРТЫБЫЗ. ЧИСТАЛЫКНЫ ҺӘМ АНДАГЫ ТӘРТИПНЕ САКЛАУ –ҺӘР УКУЧЫНЫҢ БУРЫЧЫ. АЯК КИЕМЕҢНЕ САЛГАЧ, ПАРЛАП ҺӘМ ТӘРТИПЛӘП КУЙ!





## -КАРМАК-

***Мәктәп сумкасы чаң кага.***

Мәрмәр өстендә ятсам да,
Минем урын түбәндә.
Әйт әле, зинһар , хуҗама
Аунатмасын идәндә.

# Онытма!

**Дүшәмбе – Мәктәпкүләм линейка.**

**Сишәмбе – Яңалыклар сәгате.**

**Чәршәмбе – Сәламәтлек сәгате.**

**Пәнҗешәмбе – Сыйныф җыелышлары.**

**Җомга – Сыйныф сәгате.**

**Шимбә – Дәрестән соң сыйныф бүлмәләрен җыештыру.**